ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 07.10.2020 г. Казань № 106-3/т-2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Норматив хокукый актны актуальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карарына кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.10.2020 № 106-3/т-2020 карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибе (алга таба – Тәртип) автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуны гамәлгә ашыру нәтиҗәләренең сыйфатын һәм үтемлелеген арттыру, Татарстан Республикасы территориясендә даими нигездә файдаланыла торган маршрутлар буенча пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару хезмәтләреннән файдаланучыларның икътисадый мәнфәгатьләрен яклау, хезмәтне гамәлгә ашыручы затлар һәм әлеге хезмәтләрдән файдаланучы затлар арасында мәнфәгатьләр нисбәтенә ирешү максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими нигездә файдаланыла торган маршрутлар буенча даими рәвештә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга тарифларны (алга таба – пассажирлар һәм йөртү  багаж алып баруга тариф) дәүләт тарафыннан җайга салуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифлар буенча гамәлләр тәртибен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

тарифларны формалаштыру – гариза, кирәкле документлар һәм нигезләү материаллары әзерләү һәм тапшыру (алга таба – гариза һәм документлар), шулай ук тарифларны билгеләү турындагы тәкъдимнәрне карау процедурасы;

гариза – Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына (алга таба – Дәүләт комитеты, җайга салу органы) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга, шулай ук дифференциацияләнгән тарифлар билгеләү (алга таба – тарифлар билгеләү) турында әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча мөрәҗәгать итү.

Гаризага тарифларны җайга салу өлкәсендә законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә, шулай ук әлеге Тәртипнең 22 пункты һәм 2 һәм 3 нче кушымталары нигезендә документлар теркәлә.

Гариза бирүче булып заказ бирүче тора, документларны транспорт белән алып бару хезмәте күрсәтүче зат(лар) формалаштыра;

заказ бирүче – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы яисә транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат белән дәүләт контрактын яисә муниципаль контрактын төзи торган вәкаләтле җирле үзидарә органы;

транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат – дәүләт контракты яисә муниципаль контракт нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән пунктка пассажирны һәм багажны алып бару йөкләмәсен үз өстенә алган юридик зат, шәхси эшкуар;

эксперт – тарифлар билгеләү (тапшырылган документларны тикшерү, анализлау) һәм тарифларны исәпләүне гамәлгә ашыручы Дәүләт комитеты хезмәткәре;

тарифларны билгеләү турында эксперт бәяләмәсен әзерләү – әлеге Тәртип нигезләмәләре нигезендә тәкъдим ителгән гаризалар һәм документлар буенча дәлилләнгән һәм икътисадый нигезләнгән нәтиҗәләрне һәм тәкъдимнәрне карауны, шулай ук формалаштыруны үз эченә алган чаралар комплексы;

база чоры – җайга салу чорына (исәп-хисап елына) кадәрге календарь елы;

җайга салынулы чор – тарифлар билгеләнә торган чор (ел);

3. Пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу, оешу-хокук формаларына, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыручы транспорт йөртүче(ләр)гә кагыла.

4. Заказ бирүче(ләр) ел саен, елына бердән артык булмаган күләмдә мөрәҗәгать итә(ләр).

5. Тарифлар билгеләү (үзгәртү) турында гариза заказ бирүче(ләр) тарафыннан җайга салу органына кәгазьдә һәм USB-флеш-туплагычында (алга таба – электрон туплагыч) электрон рәвештә яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган Бердәм мәгълүмат-аналитика системасының төбәк сегментындагы үрнәк форматында җибәрелә.

Гариза һәм аңа теркәлә торган хат заказ бирүче зат(лар)ның җитәкчесе (җитәкчеләре) тарафыннан имзаланган һәм (булган очракта) заказчы(лар) ның мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.

Гариза белән берлектә заказ бирүче(ләр) нигезли торган документларны да җибәрә(ләр).

Документлар тегелгән, номерланган, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның вәкаләтле заты (кимендә җитәкче урынбасары) тарафыннан таныкланган һәм документлар реестрын теркәп, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның мөһере белән беркетелгән булырга тиеш. Документлар реестрында кәгазьдә бирелә торган документлар исемлеге һәм электрон файлларның каталогы булырга тиеш. Файлларның һәм папкаларның электрон чыганактагы атамасы документларның эчтәлеген һәм аларны формалаштыру датасын (вакытын) чагылдырырга тиеш. Электрон чыганактагы файллар чыгымнар структурасы, бирелә торган документларның төрләре һ.б. нигезендә системалаштырылырга тиеш.

Коммерция һәм хезмәт серен үз эченә алган документлар закон таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.

Заказ бирүче(ләр) тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимне карау кысаларында өстәмә документлар тапшырырга хокуклы.

6. Гаризаларны кабул итү һәм теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

7. Җайга салу органына тиешле срокта дәлилләү документларын тапшырмаган яки белә торып дөрес булмаган белешмәләр биргән өчен заказчы(лар) һәм транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә җаваплы була.

8. Җайга салынулы тарифларны билгеләү (тикшерү, анализлау) турындагы тәкъдимне карап тикшерү, пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга тарифларны исәпләү транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның түбәндәге вазыйфаларыннан чыгып гамәлгә ашырыла:

8.1. дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле эшчәнлек төрләре буенча тарифлар билгеләү мәсьәләләре буенча мәгълүмат, документлар тапшыру;

8.2. даими рәвештә пассажирлар алып бару төрләре (җайга салына һәм салынмый торган тарифлар буенча), транспорт төрләре (автомобиль транспорты, җир өсте шәһәр электр транспорты (трамвай, троллейбус), шулай ук тариф төрләре буенча күләмле күрсәткечләрне, керемнәрне, чыгымнарны (сарыфларны) һәм финанс нәтиҗәләрен аерым исәпкә алып бару;

8.3. эшчәнлекнең җайга салынулы төрләренә гомумпроизводство, гомумхуҗалык һәм башка бүленгән чыгымнарның нигезле рәвештә кертелүен ачыклау максатларында эшчәнлекнең барлык төрләре буенча мәгълүмат, документлар тапшыру.

9. Тарифларны билгеләү турында гаризаны (тәкъдимне) карау нәтиҗәсе түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

9.1. тарифларны билгеләү турында карар кабул итү;

9.2. тариф эшен ачудан баш тарту турында карар кабул итү.

10. Тарифлар бер елдан да ким булмаган вакытка билгеләнә.

## II. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга тарифлар билгеләү тәртибе һәм үзенчәлекләре

11. Салым һәм бухгалтерлык исәбе турындагы законнар нигезендә транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) тарафыннан хисап елын ябу нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә 2 нче һәм 3 нче кушымталар һәм 22 пункт нигезендә транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) тарафыннан формалаштырылган документларны теркәп, гариза тапшырыла торган елның 1 июленнән соңга калмыйча (2022 елның җайга салу чорына һәм алдагы елларга) заказ бирүче(ләр)нең Дәүләт комитетына гариза белән мөрәҗәгать итүе тарифлар билгеләү турындагы мәсьәләне карау нигезе булып тора.

2021 елның җайга салу чорына гариза заказ бирүче(ләр) тарафыннан 9 ай өчен транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) тарафыннан арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын формалаштыру нәтиҗәләре буенча, ләкин 2020 елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Заказ биръче(ләр) тарафыннан гариза һәм әлеге Тәртипнең 22 пунктында һәм 2 һәм 3 кушымталарында каралган нигезләү документлары тапшырылмаган очракта,

җайга салу органы транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре нигезендә, шулай ук җайга салуның алдагы чорлары өчен булган, шул исәптән гамәлдәге тарифларны билгеләү өчен кулланылган, белешмәләргә карап та, тарифлар билгеләү турындагы мәсьәләне карый.

Бу очракта җайга салу органы заказ бирүче(ләр)дән әлеге Тәртипнең 22 пункты һәм 2 нче һәм 3 нче кушымталары нигезендә формалаштырылган, нигезли торган документларны сората. Заказ бирүче(ләр) тарафыннан документларны тапшыру вакыты документларны тапшыру турында соратылган мөрәҗәгать алынган көннән соң 20 эш көне тәшкил итә. Заказ бирүче(ләр)нең язма мөрәҗәгате буенча документларны тапшыру вакыты җайга салу органы тарафыннан озайтыла, ләкин иң күбе 20 эш көненә кадәр генә.

12. Җайга салу органы гаризаны теркәгәннән соң 14 эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 22 пунктында һәм 2 нче һәм 3 нче кушымталарында санап үтелгән барлык документларның булуын, аларның законнардагы һәм әлеге Тәртип таләпләренә (комплектлылыгы, формасы, эчтәлеге буенча) туры килүен тикшерә.

Тарифлар билгеләү өчен барлык документлар булган очракта, алар законнардагы таләпләргә, әлеге Тәртипнең 22 пунктына һәм 2 нче, 3 нче кушымталарына туры килгәндә, тариф эшен ачу турында карар кабул ителә, бу хакта җайга салу органы заказ бирүче(ләр)гә мондый карар кабул ителгән вакыттан башлап 5 эш көне узганчы (почта юлламасы, электрон документ әйләнеше яисә электрон почта ярдәмендә) хәбәр итә.

Документлар тулы исемлеге буенча тапшырылмаган очракта, яисә тапшырылган документлар тарифларны җайга салу, бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык өлкәсендәге законнарның таләпләренә, әлеге Тәртипнең 22 пунктына һәм 2 нче, 3 нче кушымталарына туры килмәсә, җайга салу органы документларны тикшереп бетергән вакыттан соң 5 эш көне узганчы заказ бирүче(ләр)дән документларны сората.

Заказ бирүче(ләр) җайга салу органы тарафыннан соратыла торган документларны сорату мөрәҗәгате алынганнан соң 14 эш көне эчендә теркәлә торган хат белән берлектә һәм документлар исемлеген теркәп тапшыралар.

13. Заказ бирүче(ләр) сорала торган документларны билгеләнгән чорда тапшырмаса яисә документларны анализ һәм исәп-хисап ясау өчен җитәрлек булмаган күләмдә тапшырган очракта, җайга салу органы тариф эшен ачудан баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта Дәүләт комитеты заказ бирүче(ләр)гә сорала торган документларны тапшыру вакыты узганнан соң 5 эш көне узганчы (почта юлламасы, электрон документ әйләнеше яисә электрон почта ярдәмендә) хәбәр итә.

Баш тарту законнарда һәм әлеге тәртиптә каралган тәртиптә баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң җайга салу органына кабат мөрәҗәгать итү өчен киртә булып тормый.

14. Тарифлар билгеләү турында карар кабул итү срогы (тариф эше ачылган көннән башлап), әлеге Тәртипнең 15 пунктыннан тыш, 90 календарь көне тәшкил итә.

15. Тариф эше ачылганнан соң нигезли торган өстәмә документларны тапшыру зарурлыгы (шул исәптән мәгълүматларның бер-берсенә каршы килү, төгәлсезлек очраклары һ.б. ачыкланса) килеп чыкса, Дәүләт комитеты заказ бирүче(ләр)гә нигезли торган өстәмә документларны тапшыру турында соратып, (почта юлламасы,

электрон документ әйләнеше яисә электрон почта ярдәмендә) мөрәҗәгать юллый, аларны тапшыру формасын һәм вакытын күрсәтә, ләкин ул 10 эш көненнән артык була алмый.

Заказ бирүче(ләр) Дәүләт комитетының мотивлаштырылган таләбе нигезендә әлеге пунктта каралган таләпләр нигезендә өстәмә документларны тапшыра(лар).

Заказ бирүче(ләр) тапшырган өстәмә мәгълүматны җайга салу органы тариф эшенә теркәп куя, шул ук вакытта тарифлар билгеләү турында карар кабул итү вакыты заказ бирүче(ләр) нигезле торган өстәмә документларны тапшырган көннән башлап 10 эш көненә озайтыла.

16. Соратыла торган документлар заказ бирүче(ләр) тарафыннан тапшырылмаган очракта, Дәүләт комитеты җайга салуның алдагы чорларына булган, шул исәптән гамәлдәге тарифларны билгеләү өчен кулланылган белешмәләргә таянып эш итә, шулай ук, аларда булган белешмәләрне төгәенләштерү өчен, документларны биргән вәкаләтле органнарга яки оешмаларга мөрәҗәгать итә, һәркем файдалана ала торган дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларын куллана.

17. Җайга салу органы чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифларны, шул исәптән заказ бирүче (транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат) тәкъдиме буенча дифференциацияләнгән тарифларны билгели.

Дифференциацияләнгән тарифлар өлешендә җайга салу дифференциацияләүнең һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән шартларның максатчанлыгын икътисадый нигезләү принципларына нигезләнә.

18. Дифференциацияләнгән тарифлар транспортта йөрү өчен түләү ысулларына, шулай ук пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару хезмәтләрен күрсәтү шартларына бәйле рәвештә билгеләнә ала.

19. Дифференциацияләнгән тарифлар һәр төр транспорт өчен юнәлеш төрләре буенча бердәй билгеләнә.

20. Тарифлар билгеләнгәндә җайга салу органы җайга салынулы эшчәнлек алып баручы, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның икътисадый нигезләнмәгән чыгымнарын исәпләмәләрдән төшереп калдыра.

21. Әгәр транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) җайга салынулы эшчәнлектән тыш эшчәнлекнең башка төрләрен гамәлгә ашырса, аларны гамәлгә ашыруга һәм әлеге төр эшчәнлектән алынган чыгымнар тарифларны исәпләгәндә исәпкә алынмый.

22. Тарифлар билгеләү максатларында транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) түбәндәге, заказ бирүче(ләр) белән килештерелгән документларны (төп нөсхәләрдә яки тиешле рәвештә таныкланган күчермәләрдә) формалаштыра(лар):

22.1. Битләренә номер сугылган тапшырылган документлар реестры. Реестрда һәр томдагы документлар исемлеген һәм электрон файлларның каталогын күрсәтеп, тариф эше томнары саны турында мәгълүмат булырга тиеш.

22.2. Тарифлар билгеләү зарурлыгы сәбәпләрен нигезләп, шул исәптән дәүләт программалары кысаларында алынган керемнәрне күрсәтеп, җайга салу чорына транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) эшчәнлегендә производство күрсәткечләренең үзгәрүе турында, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның карап тоту һәм эксплуатацияләү чыгымнары җайга салына торган эшчәнлек төренә карый торган төп фондларны куллануга бәйле эшләрне башкару

(хезмәтләр күрсәтү) буенча керемнәре турында, производство чыгымнарын оптимальләштерү, энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, пассажирлар хәрәкәтен арттыру чаралары турындагы мәгълүмат белән аңлатма язуы.

22.3. Норматив акт белән расланган даими маршрутлар реестры.

22.4. База алдыннан килгән чорга һәм база чорына булган белешмәләрне тапшырып, пассажирлар агымын тикшерү нәтиҗәсе (маршрут номерын һәм исемен, уздыру датасын, пассажирлар агымын тикшерүдә катнашучы транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат һәм гариза бирүче зат ягыннан вазыйфаи затларны күрсәтеп). Ирекле формада тутырыла.

22.5. Заказ бирүче тарафыннан расланган паспорт һәм маршрут расписаниесе күчермәләре.

22.6. Җайга салу чорына дәүләт яки муниципаль контрактның күчермәсе, сатып алуның идентификация кодын, zakupki.gov.ru бердәм мәгълүмат системасы сайтында урнаштырылган контрактның реестр номерын күрсәтеп.

22.7. Заказ бирүче тарафыннан расланган даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документы күчермәсе.

22.8. Субсидияләр бирү турында төзелгән килешүләрнең (шартнамәләрнең) күчермәләре. Алынмаган керемнәрне каплатуга, шул исәптән ташламалы категориядәге пассажирлар йөртүгә бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре, дотацияләр, компенсацияләр (план, факт) турында заказ бирүчедән белешмә (чорлар: база чорыннан алдагы, база һәм җайга салу чорлары).

22.9. Гамәлгә кую документларының күчермәләре, эшчәнлекнең җайга салынулы төрләренә лицензияләр күчермәләре (булган очракта).

22.10. Исәпкә алу сәясәте (база чорыннан алдагы, база һәм җайга салу чорлары) турында боерык һәм нигезләмә күчермәсе.

22.11. Штат расписаниесен раслау турындагы боерык күчермәсе, премияләү турында нигезләмә күчермәсе (база чорыннан алдагы, база һәм җайга салу чорлары).

22.12. Автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең маршрут челтәре параметрларына туры килү турында белешмәләр (заказчы тарафыннан таныкланган).

22.13. Бухгалтерлык хисаплылыгы күчермәләре (барлык кушымталар белән бухгалтерлык балансы), салым салу системасын куллану турында салым органы белдерүенең күчермәсен, хезмәтләрнең үзкыйммәтенә керә торган, исәпләнгән салымнар буенча декларацияләрне теркәп (база чорыннан алдагы, база һәм җайга салу чорлары).

22.14. База чорыннан алдагы һәм база чорына статистика хисаплылыгы (№ 1-Т «Хезмәткәрләр исәбе һәм аларның хезмәт хакы турында белешмәләр», № 65-автотранс «Пассажирлар өчен автомобиль транспорты эшчәнлеге турында белешмәләр», № 65-ЭТР «Шәһәр электр транспорты турында белешмәләр», № 1-автотранс «Даими маршрутлар буенча автобуслар эше турында белешмәләр»).

22.15. Производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминият кертемнәренең күләме турында белдерү.

22.16. Хәрәкәт составын яңарту, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү буенча төп фондларның чараларын гамәлгә ашырганда заказчы тарафыннан расланган инвестициясе программасы, финанслау чыганакларын, финанслау планын, шулай ук

әлеге Тәртипнең 7 нче, 9 нчы кушымталарына ярашлы рәвештә кәтелгән нәтиҗәне күрсәтеп.

Җайга салу органы инвестицион программада каралмаган чараларны финанслау чыгымнарын тарифларны билгеләгәндә исәп-хисаплардан төшереп калдыра.

22.17. Экплуатация һәм башка күрсәткечләргә, нигезли торган документларның күчермәләрен (шул исәптән транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның транспорт чараларына капиталь һәм агымдагы ремонтны уздыру, чыгым материаллары нормативларын, чыгымнарны ремонтка юнәлдерү нормативларын һ.б. раслау буенча эчке документларның (боерыкларның) күчермәләре) теркәп, гамәлдәге нормалар һәм чыгым нормативлары.

22.18. Автомобиль транспорт чараларына милек (яки файдалану) хокукын раслый торган документларның күчермәләре, транспорт чараларына техник паспортларның күчермәләре.

22.19. Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше фаразында билгеләнгән төп параметрлардан (индекслардан) артып киткән, база чорында тайпылышлары булган чыгымнар статьяларына һәм башка күрсәткечләргә аңлатма ирекле формада тапшырыла. База чоры белән чагыштырганда чыгым статьяларын үзгәрткәндә һәр статья буенча беренчел бухгалтерлык документлары нигезендә чыгымнарны арттыруга (киметүгә) нигезләү бирелә.

22.20. Керемнәрен, чыгымнарын һәм күләм күрсәткечләрен (шартнамәләр (килешүләр), эчке документлар, товар кәгазьләре, счет-фактуралар, башкарылган эшләрнең актлары, бухгалтерия документлары (реестрлар, ведомстволар һ.б.), прайслар) раслый торган документларның күчермәләре.

22.21. Әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә даими рәвештә автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) эшчәнлегендә финанс-икътисад һәм күләм күрсәткечләре.

22.22. Әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә даими маршрутлар буенча җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) эшчәнлегенең финанс-икътисад һәм күләм күрсәткечләре.

22.23. Транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)га карата тикшерү чараларын, планлы (рейд) карауларын, автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын үтәү предметы буенча транспорт чараларына тикшерүләр уздырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольлек органнары күрсәтмәләре.

Җайга салу органына тикшерү чаралары нәтиҗәсендә ачыкланган кисәтүләрне бетерү (бетерү буенча күрелгән чаралар) турында мәгълүмат тапшырырга кирәк.

22.24. Җайга салу чорына күчмә составны, биналарны, корылмаларны, контакт-кабель челтәрләрен ремонтлау планнарының күчермәләре, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның транспорт чараларына, биналарга һәм корылмаларга, контакт-кабель челтәрләренә капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрүне раслый торган документларының (боерыкларның, башкарылган эшләр актларының) күчермәләре, гамәлдәге тарифта исәпкә алынган, алдагы чор өчен инвестиция чараларыннан, капитал кертемнәреннән файдалану буенча хисаплар..

22.25. Салым органы тарафыннан барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булмавы турында таныкланган белешмә (тарифлар билгеләү турында гариза тапшырылган датага һәм гариза бирелгән елдан алда килгән елның 31 декабренә).

22.26. Җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) тарафыннан сатып алу модуле – «Биржа мәйданчыгы» электрон ресурсы агрегаторында гамәлгә ашырылган сатып алулар турында белешмәләр (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгаруга идарә итү системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлек итү регламентын раслау турында» 2019 елның 4 маендагы 377 номерлы карарының 6 пунктын үтәү максатында).

22.27. Җайга салу органы тарафыннан транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның икътисадый яктан нигезләнгән чыгымнарын раслый торган башка төрле өстәмә документлар соратылырга мөмкин.

23. Тариф эшләрен анализлау нәтиҗәләре буенча тарифлар билгеләүгә бәяләмә һәм тарифлар билгеләү турында (тарифларны билгеләүдән баш тарту турында) Дәүләт комитеты карары проектына бәяләмә әзерләнә, ул сәнәгать булмаган өлкә тарифларын җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге башлыгы, юридик бүлек башлыгы һәм җитәкчелек итүче урынбасар тарафыннан килештерелә.

24. Тарифлар билгеләү турындагы карар проекты Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, иҗтимагый оешмалар һәм федераль дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары вәкилләре катнашында Килештерү комиссиясе утырышында карала.

25. Тарифлар билгеләү турында карар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында кабул ителә.

26. Тарифлар чираттагы еллык җайга салу чорының беренче ярты елында әлеге тарифларның күләме 31 декабрь торышына алдагы еллык җайга салу чорының икенче ярты елында тиешле тарифлар күләмен арттырмаган зурлыкка карап, яртыеллык буенча календарь нигезендә бүлеп билгеләнә.

## III. Тарифларны исәпләү тәртибе

27. Тарифлар транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) тапшырган нигезләү документлары, әлеге Тәртипнең 2 нче һәм 3 нче кушымталарына ярашлы формалар буенча хисап һәм фараз күрсәткечләре нигезендә исәпләнә.

28. Тарифларны дифференциацияләү җайга салу органы тарафыннан заказ бирүче(ләр) тәкъдиме буенча, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) эшчәнлегенең финанс-икътисад һәм җитештерү күрсәткечләренә, маршрутларның сыйфатламаларына, юлда барган өчен түләү ысулларына һәм хезмәтләрне күрсәтү шартларына карап, алып барылган пассажирларның фаразланган күләмен һәм яки пассажирлар хәрәкәтен исәпкә алып билгеләнә.

Дифференциацияләнгән тарифлар буенча исәпләнгән җыелма керем Дәүләт комитеты тарафыннан тарифны исәпләү өчен кабул ителгән кирәкле тулай табыш күләменнән артмаска тиеш.

Үзләренә карата элегрәк җайга салу гамәлгә ашырылмаган транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар), маршрутлар, транспорт чаралары төрләре буенча дифференциацияләнгән тарифлар билгеләнгән очракта, тарифлар, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) эшчәнлегенең планлаштырыла торган финанс-икътисадый һәм җитештерү күрсәткечләре нигезендә һәм (яки) аналогларны чагыштыру алымын кулланып исәпләнә.

29. Татарстан Республикасы территориясендә даими муниципаль яки муниципальара маршрутлар буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтү транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтә торган ике һәм аннан да күбрәк зат тарафыннан гамәлгә ашырылган очракта, әлеге Тәртипнең 22 пунктында һәм 2 нче һәм 3 нче кушымталарында санап кителгән документлар заказ бирүчегә транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче барлык затлар тарафыннан җибәрелә.

Бу очракта транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче затлар тарафыннан алып барылырга тиешле пассажирларның (шәһәр элемтәсендә) планлаштырылган күләменә яки пассажирлар хәрәкәтенең планлаштырыла торган күләменә (шәһәр яны һәм шәһәрара элемтәләрдә) карата кирәкле тулай керем нисбәте буларак бердәм тариф исәпләнә.

30. Тарифларны исәпләгәндә күләм күрсәткечләре (пассажирлар саны, пассажирлар хәрәкәте) заказ бирүче тарафыннан расланган транспорт хезмәте күрсәтүгә заказ нигезендә, пассажир агымнарын тикшерү мәгълүматлары, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче затларның алдагы өч елда күләм күрсәткечләре динамикасы нигезендә кабул ителә.

Әгәр алдагы чорда алып барылган пассажирлар күләме турында мәгълүматлар булмаса, алып барылачак пассажирларның планлаштырылган күләме исәп-хисап нигезендә кабул ителә, ләкин транспорт чарасының сыйдырышлылыгы шундый ук маршрутларда уртача күләменнән ким булмаска тиеш, яисә заказ бирүче тарафыннан расланган халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә заказ нигезендә кабул ителә.

31. Тарифларны җайга салганда түбәндәге методлар кулланыла:

- икътисадый яктан нигезләнгән чыгымнар методы, бу вакытта тарифлар әлеге Тәртипнең 33 пункты нигезендә кирәкле тулай табышны күрсәтелгән хезмәтләр күләменә бүлүдән килеп чыккан күрсәткеч буларак билгеләнә;

- тарифларны индексацияләү методы, ул җайга салу чорына Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан эшләнгән Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразының база вариантында кулланучы бәяләренә индекс-дефляторны исәпкә алып элегрәк билгеләнгән тарифларны индексацияләүне күздә тота.

Озак сроклы тарифлар билгеләнгәндә (1 елдан артыграк вакытка) тарифларны индексацияләү методы кулланыла.

Дәүләт комитетына тапшырылган закон һәм әлеге Тәртип нигезендә рәсмиләштерелгән, документаль расланган чыгымнар (сарыфлар) нигезле дип таныла.

32. Җайга салу чорына тарифлар исәпләнгәндә (икътисадый нигезләнгән чыгымнар методы белән) җайга салына торган эшчәнлекнең күләм күрсәткечләре (алып барылган пассажирлар саны, пассажиркилометрлар, рейслар саны) алдагы өч елга җайга салына торган эшчәнлекнең даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга дәүләт яки муниципаль контрактларда каралган күләм

күрсәткечләре динамикасын, җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруның чагыштырма шартларында күләм күрсәткечләре статистикасын һәм күләм күрсәткечләренең үзгәрүеннигезли торган документларны исәпкә алып, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) тәкъдименә карап кабул ителә.

Транспорт чараларының һәр маршрут буенча тулу коэффициенты әлеге формула буенча исәпләнә:

$$Кн = Пт / \sum_{i=1}^{n} (Bmi * Pi) * 100\%,$$ биредә

Кн — маршрут буенча транспортның тулу коэффициенты;

Пт — җайга салу чорына транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат фаразлаган пассажирлар хәрәкәте;

Bmi — i-нче (нчы) транспорт чарасының тулучанлыгы (пассажирлар саны);

Pi — i-нче (нчы) транспорт чарасы хәрәкәтенең расланган расписание һәм транспорт хезмәтләре күрсәтүгә заказ нигезендә җайга салу чорына транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат фаразлаган маршрут аралыгы белән рейслар исәбенең тапкырчыгышы буларак исәпләнгән ераклыгы.

n – әлеге маршрутта йөри торган транспорт чаралары исәбе.

33. Пассажирлар алып баруга тариф әлеге формула буенча исәпләнә:

$$T = НВВ / П,$$ биредә

НВВ – кирәкле тулай керем;

П – пассажирлар хәрәкәте яки, тарифның үлчәү берәмлегенә карап, алып барылган пассажирлар саны.

33.1. Кирәкле тулай керем әлеге формула буенча исәпләнә

$$НВВ = Рэ + Пр,$$ биредә

Рэ – пассажирлар алып бару хезмәтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле икътисадый нигезләнгән чыгымнар;

Пр — халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне яхшыртуга, транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның техник һәм технологик җиһазланыш дәрәҗәсен үстерүгә, социаль түләүләр һәм башка чараларга юнәлдерелгән чараларны финанслау өчен кирәкле керем суммасы.

33.2. Икътисадый нигезләнгән чыгымнар әлеге формула буенча исәпләнә:

$$Рэ = Рпр + Роп + Рох,$$ биредә

Рпр — эш чыгымнары;

Роп – гомумпроизводство чыгымнары;

Рох – гомумхуҗалык чыгымнары.

34. Гомуми файдаланудагы шәһәр транспортында даими муниципаль маршрутларда рөхсәт ителгән бер багажны алып барган өчен тариф бер пассажирга бер тапкыр бару тарифы күләмендә билгеләнә.

Шәһәр яны элемтәсендә даими муниципаль (муниципальара) маршрутларда бер урын алып баруга рөхсәт ителгән бер урынлы багажны алып барган өчен тариф пассажирлар алып бару тарифының 15% күләмендә билгеләнә.

Шәһәрара элемтәдә даими муниципальара маршрутларда алып бару өчен рөхсәт ителгән бер урынлы багажга тарифлар түбәндәгечә билгеләнә:

300 км кадәрге маршрут буенча пассажирлар алып барганда – пассажир алып баруга тарифның 15% күләмендә;

300 км артып китүче маршрут буенча пассажирлар алып барганда – пассажир алып баруга тарифның 10%.

35. Шәһәр элемтәсендә даими муниципаль маршрутлар буенча тарифлар билгеләнгәндә, пассажирлар белән исәп-хисап ясарга уңайлы булсын өчен, аларның күләме бер сумга кадәр төгәллек белән билгеләнә (50 тиенгә кадәр булганда – исәпкә алынмый, 50 тиеннән артыграк булганда бер тулы сумга кадәр түгәрәкләнә).

36. Дәүләт комитеты исәпләнгән тариф күләмен килештерү өчен заказ бирүчегә җибәрә.

## IV. Тарифларны исәпләгәндә чыгымнарны исәпкә алуның төп нигезләмәләре

37. Кирәкле җыелма керемгә кертелә торган чыгымнар составын билгеләү Россия Федерациясе Салым кодексы, салым салу максатларында транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) кабул иткән исәп сәясәте нигезендә башкарыла.

38. Кирәкле җыелма керем җайга салынулы эшчәнлек буенча чыгымнарны тулысынча каплау һәм табыш хисабына чыгымнарны финанслау һәм үстерү өчен кирәкле табыш алу өчен транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) өчен кирәкле акчаларның исәп-хисап күләме буларак билгеләнә.

39. Транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның чыгымнары, чыгымнарның гамәлдәге нормативларын һәм аларның икътисадый нигезләнешен исәпкә алып, җайга салу органы тарафыннан анализланырга тиеш.

Тарифларны исәпләгәндә җайга салу органы производство ресурсларыннан рациональ файдаланмау аркасында барлыкка килгән чыгымнарны һәм федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) муниципаль берәмлекләр бюджеты хисабыннан финансланырга тиешле чараларны гамәлгә ашыруга тиешле акчаларны, шулай ук җайга салынулы эшчәнлек белән бәйле булмаган чыгымнарны исәпкә алмый.

40. Транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның чыгымнары производство чыгымнарын (эшчәнлекне җайга салуга турыдан-туры бәйле – транспорт чараларын эксплуатацияләү һәм карап тоту чыгымнары); гомумпроизводство чыгымнарын; гомумхуҗалык чыгымнарын (эшчәнлеккә идарә итү һәм хезмәт күрсәтү чыгымнары) үз эченә ала.

41. База чорыннан алдагы, база һәм җайга салу чорлары (еллар) өчен транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның эшчәнлек чыгымнары пассажирлар йөртү маршрутларының төрләре (җайга салына һәм җайга салынмый торган тарифлар буенча, шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә даими муниципаль һәм муниципальара маршрутлар буенча) арасында тиешле елга транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның исәп сәясәтендә каралган күрсәткечкә пропорциональ рәвештә бүленә.

База чорыннан алдагы, база һәм җайга салу чорлары (еллар) өчен гомумпроизводство һәм гомумхуҗалык чыгымнары эшчәнлек төрләре һәм маршрутлар буенча тиешле елга транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче

зат(лар)ның исәп сәясәтендә каралган күрсәткечкә яки тиешле елга эшчәнлек чыгымнары күрсәткеченә пропорциональ бүлгәләнә.

Чыгымнарны бүлгәләү максатында даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару хезмәтләре күрсәтүдән алынган табыш суммасы билгеләнгән (билгеләү өчен тәкъдим ителә торган) тариф дәрәҗәләренә һәм алып барылган пассажирларның исәпкә алынган исәбенә һәм пассажирлар хәрәкәтенә карап билгеләнә.

Билгеле бер ешлыкта гамәлгә ашырыла торган чараларга чыгымнар хокукый актларда яки транспорт белән баручы зат(лар) тарафыннан билгеләнгән ешлыкка карап тарифта тигез өлешләрдә исәпкә алына.

42. Транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның чыгымнары чыгымнарның түбәндәге статьялары буенча исәпкә алына:

хезмәт хакы – пассажирларга хезмәт күрсәтү, транспорт чараларын эксплуатацияләү һәм агымдагы карап тоту буенча төп эшчәнлек персоналының һәм административ-идарә персоналының хезмәт хакы фонды. Персоналның уртача айлык хезмәт хакы Татарстан Республикасы территориясендә узып киткән иң якын хисап чорына икътисадның барлык тармакларындагы эре һәм урта предприятиеләрдә һәм коммерциясез оешмаларда эшләүчеләргә исәпләнгән уртача айлык номиналь хезмәт хакының дәүләт статистикасы органы тарафыннан бастырып чыгарылган һәм агымдагы чорга һәм җайга салу чорына фаразның база вариантында билгеләнгән индекслар белән җиткерелгән күләменнән артмаска тиеш;

иминият кертемнәре – Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри иминиятләштерү килешүләре буенча түләүләр (кертемнәр);

ягулык, электр энергиясе, майлау материаллары – ягулык, майлау материаллары һәм электр энергиясе сатып алу чыгымнары;

төп фондларны амортизацияләү – транспорт чараларын, биналарны, корылмаларны, җайланмаларны, башка төп чараларны амортизацияләү.

Төп фондларны (биналар, корылмалар, машиналар, җиһазлар, транспорт чаралары һ.б.) тулысынча торгызуга амортизация кертемнәре исәпләү аларны файдалы куллану вакытына бүленгән беренчел яки торгызу бәясеннән чыгып башкарыла;

аренда (лизинг) – чит оешмалар белән транспорт чараларын арендалау (лизинг) килешүләре буенча чыгымнар;

ремонт – транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау (агымдагы, урта, капиталь), авторезинны ремонтлау, трамвай линияләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау, шулай ук биналар һәм корылмаларны (юлларны һәм контакт-кабель челтәрләрен) ремонтлау чыгымнары.

Ремонтка киткән чыгымнарга түбәндәгеләр керә:

- ремонт персоналының хезмәт хакы һәм иминият кертемнәре, ремонтка бәйле командировка чыгымнары;
- ремонт өчен кирәкле материалларга чыгымнар;
- ремонт эшләренә килешүләр буенча чыгымнар.

Резерв ремонт фондын төзи торган транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) аны үзкыйммәтенә кертә.

Әгәр транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) резерв ремонт фондын төземәсә, ул вакытта транспорт чараларына урта һәм капиталь ремонт чыгымнары тарифта ремонт уздыру ешлыгына карап яки транспорт белән алып бару

хезмәтен күрсәтүче зат ремонтка билгеләгән нормативларга карап тигез өлешләрдә исәпкә алына;.

- башка чыгымнар – килешүләр буенча чыгымнар (ремонт эшләренә, транспорт чараларының аренда (лизинг) чыгымнарыннан тыш), салымнар, үзкыйммәткә кертелә торган түләүләр, коммуналь түләүләр, исәпкә алынмаган башка чыгымнар.

43. Җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыру чыгымнарын анализлаганда автомобиль, җир өсте шәһәр электр транспорты өлкәсендә гамәлдәге нормативлар, материалларга уртача бәяләр һәм Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсешен фаразлауның параметрлары исәпкә алына.

44. Транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның җайга салу чорына чыгымнарын фаразлау түбәндәгеләрне кулланып гамәлгә ашырыла:

- дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) һәм аларның фараз күрсәткечләрен;

- җайга салу чорына Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан эшләнгән Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразының база вариантында билгеләнгән фараз күрсәткечләрен;

- Россия Федерациясе законнарында каралган башка нигезләр буенча сатулар үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелгән килешүләр нигезендә билгеләнгән бәяләрне;

- дәүләт статистикасы органы бастырып чыгарган бәяләр турында мәгълүматны.

Җайга салу чорына чыгымнарның аерым статьяларын үзгәртү түбәндәге уртача еллык индекслар белән чикләнә:

- хезмәт хакы - инфляция индексы (җайга салу чорына Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан эшләнгән Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразының база вариантында билгеләнгән кулланучы бәяләре индексы);

- ягулык-нефть продуктлары җитештерүгә бәяләр индексы;

- электр энергиясе – барлык кулланучылар категорияләре өчен электр энергиясенә бәяләр индексы, халыктан тыш;

- материаллар, аренда (лизинг), башка чыгымнар — ягулык-энергетика комплексы продукциясеннән башка эчке базар өчен сәнәгать продукциясе җитештерүчеләрнең бәяләрен үзгәртү индексы.

45. Фаразлана торган индексларга караганда чыгымнарны (чыгымнарның статьялары буенча) үзгәртү күләмен арттыру заказ бирүче тарафыннан килештерелгән (расланган) очракларда транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) эшендә күләм күрсәткечләре үзгәргәндә (маршрутларның схемалары, рейслар күләме һ.б. үзгәрү) яисә җайга салу яки база чорларында транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар) тарафыннан каралмаган өстәмә чыгымнарны китереп чыгара торган закаоннардагы үзгәрешләр очрагында мөмкин.

Җайга салу чорына транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат(лар)ның чыгымнарын фаразлаган вакытта транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат эшендәге күрсәткечләрнең үзгәрешләре (маршрутларның схемалары, рейсларның саны һ.б. үзгәрүе) исәпкә алына.

Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими нигездә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салына торган тарифлар билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә

Тарифлар билгеләү турында
________________________

**ГАРИЗА**

Мөрәҗәгать итүче:_______________________________________________________
(юридик затның тулы атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

Гариза бирүченең реквизитлары:_____________________________________
(ОГРН, ИНН, КПП, ОКПО, ОКАТО, ОКОГУ)

Юридик затның адресы (шәхси эшкуарның теркәү адресы): __________
________________________________________________________________________
_______________________________________________

Гариза бирүченең почта адресы: ___________________________________________
________________________________________________________________________

Оешма җитәкчесе:_____________________________________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы________________________________________________________________
(Ф.И.А.), элемтә өчен телефон, электрон почта адресы)

Элемтә өчен телефоннар, факс, электрон почта адреслары, гариза бирүченең банк реквизитлары_________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең тарифлар билгеләү өчен мөрәҗәгать итү нигезе:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән таләп (бәяләр (тарифлар) дәрәҗәсе):
______________________________________________________________________

Җайга салу чоры ______________________________________________________

Кушымта: Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына тапшырылган документлар һәм материаллар реестры (битләрен нумерацияләп).

Җитәкче ____________________ ____________________
(имза) (тулы имза)

Дата «___» _____________ 20___ ел М.У. (булган очракта)

Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими нигездә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салына торган тарифлар билгеләү тәртибенә 2 нче кушымта

# Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салына торган тарифлар билгеләү өчен документлар исемлеге

1. Халыкка автотранспорт хезмәте күрсәтүгә заказ (1 нче таблица).
2. Җитештерү-хуҗалык эшчәнлегенең төп күрсәткечләрен анализлау (2 нче таблица).
3. Автомобиль транспортында пассажирлар йөртүгә тарифлар исәпләүгә натураль һәм финанс күрсәткечләрен анализлау (3.1 һәм 3.2 таблицалар).
4. Хезмәт күрсәткечләрен анализлау (4 нче таблица).
5. Автомобиль транспортында ягулык чыгымын анализлау (5 нче таблица).
6. Пассажирлар йөртү төрләре буенча автомобиль транспортының эш күрсәткечләре (5.1 таблица).
7. Автомобиль транспортында майлау материаллары чыгымын анализлау (5.2 таблица).
8. Автомобиль транспортына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау чыгымнарын анализлау (6 нчы таблица).
9. Төп фондларның амортизацион түләүләрен исәпләү (7 нче таблица).
10. Лизинг түләүләрен анализлау (8 нче таблица).
11. Гомумхуҗалык һәм гомумэшчәнлек чыгымнарын җентекләү (9 нчы таблица).
12. Пассажирлар йөртүнең эшчәнлек төрләре буенча гомумпроизводство һәм гомумхуҗалык чыгымнарын бүлүне исәпләү (10 нчы таблица).
13. Эшчәнлек төрләре буенча маршрутлар исемлеге (11 нче таблица).
14. Пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның эшчәнлек-икътисад күрсәткечләр (12 нче таблица).
15. Автомобиль транспортында даими нигездә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга тарифлар исәпләмәсе (13 нче таблица)
16. Җирле автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыручы оешманың инвестиция программасы (14 нче таблица).
17. Автомобиль транспортында пассажирлар йөрткәндә пассажирларга хезмәт күрсәтү сыйфаты параметрлары (15 нче таблица)

1 нче таблица

Раслыйм
____________________________________________
(пассажирлар йөртүгә заказ бирүче зат җитәкчесе)
«___» ___________ 20__ ел

## _________________ маршруты (атамасы) буенча транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче зат тарафыннан __________ башлап ________ кадәрге чорда ____________ халкына автотранспорт хезмәте күрсәтүгә заказ

<table>
<tr><td>Маршрут исеме</td><td>Автобус маркасы</td><td>Маршрутның озынлыгы (маршрут паспорты нигезендә) км.</td><td>1 рейсны/рейс әйләнешен башкару өчен кирәкле вакыт, сәгать.</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Вакытлы чор (көне, ае)</td><td rowspan="2">Маршрутта эшләү көннәре саны, көн</td><td rowspan="2">Хәрәкәт аралыгы</td></tr>
<tr><td>Башлана</td><td>Бетә</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="13">Күрсәткечләрнең тәүлеклек күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td rowspan="5">Рейслар саны, данә</td><td rowspan="5">Линиядә транспорт чаралары саны, данә</td><td rowspan="5">Машина-сәгать</td><td colspan="2">Гомуми узган юл, км.</td><td colspan="7">Пассажирларның уртача саны, кеше.</td><td rowspan="5">Пассажир-хәрәкәт, пасс.км*</td></tr>
<tr><td rowspan="4">Гомуми</td><td rowspan="4">Пассажирлар белән</td><td rowspan="4">Барлыгы</td><td colspan="6">шул исәптән:</td></tr>
<tr><td colspan="5">түләүле йөрү **</td><td rowspan="3">ташламалы категория</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="4">шул исәптән</td></tr>
<tr><td>бер тапкыр алына торган билет белән</td><td>1 баруга электрон билет буенча</td><td>барулар саны чикләнгән ЭББ белән</td><td>бүтән ЭББ белән</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

* Шәһәр яны элемтәсендә пассажирлар йөртүгә тариф билгеләнгән очракта тутырыла.
** Гамәлдәге тарифларны дифференциацияләү нигезендә

2 нче таблица

_____________________________________________ производство-хуҗалык эшчәнлегенең

(транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче затның атамасы)

төп күрсәткечләрен анализлау

(мең сум)

| № т/с | Күрсәткечләрнең исеме (автобуслар) | Базага кадәрге чор | База чоры | Җайга салынулы чор | База чорына карата %ларда җайга салынулы чор |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ташылган пассажир күләме (мең кеше) | | | | |
| | шул исәптән | | | | |
| 1.1 | шәһәр элемтәсендә | | | | |
| 1.2 | шәһәр яны элемтәсендә | | | | |
| 1.3 | шәһәрара элемтәдә | | | | |
| 1.4 | Транспорт белән алып бару хезмәте күрсәтүнең башка төрләре | | | | |
| 2 | Пассажирлар хәрәкәте (мең пасс.км) | | | | |
| | шул исәптән | | | | |
| 2.1 | пассажир бара торган юлның уртача ераклыгы (км) | | | | |
| 2.2 | шәһәр яны элемтәсендә | | | | |
| 2.2 | шәһәрара элемтәдә | | | | |
| 3 | Автобусларның гомуми йөреше (мең км.) | | | | |
| | шул исәптән | | | | |
| 3.1 | шәһәр элемтәсендә | | | | |
| 3.2 | шәһәр яны элемтәсендә | | | | |
| 3.3 | шәһәрара элемтәдә | | | | |
| 3.4 | Транспорт белән алып бару хезмәте күрсәтүнең башка төрләре | | | | |
| 4 | Автобусларда эшләнгән сәгать (мең машина-сәгатьләрдә) | | | | |
| | шул исәптән | | | | |
| 4.1 | шәһәр элемтәсендә | | | | |
| 4.2 | шәһәр яны элемтәсендә | | | | |
| 4.3 | шәһәрара элемтәдә | | | | |
| 4.4 | Транспорт белән алып бару хезмәте күрсәтүнең башка төрләре | | | | |
| 5 | Эшчәнлекнең барлык төрләреннән керемнәр, барлыгы: | | | | |
| | шул исәптән | | | | |
| 5.1 | шәһәр элемтәсендә | | | | |
| 5.1.1 | шулардан бюджет компенсациясе суммасы | | | | |
| 5.2 | шәһәр яны элемтәсендә | | | | |
| 5.2.1 | шулардан бюджет компенсациясе суммасы | | | | |
| 5.3 | шәһәрара элемтәдә | | | | |
| 5.4 | Транспорт белән алып бару хезмәте күрсәтүнең башка төрләре | | | | |
| 5.5 | башка төр эшчәнлектән бүтән керемнәр | | | | |
| 6 | Чыгымнар, барлыгы: | | | | |
| | шул исәптән | | | | |
| 6.1 | шәһәр элемтәсендә | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6.2 | шәһәр яны элемтәсендә | | | | |
| 6.3 | шәһәрара элемтәдә | | | | |
| 6.4 | Транспорт белән алып бару хезмәте күрсәтүнең башка төрләре | | | | |
| 6.5 | башка чыгымнар | | | | |
| 7 | Финанс нәтиҗәләре, барлыгы: | | | | |
| | шул исәптән | | | | |
| 7.1 | шәһәр элемтәсендә | | | | |
| 7.2 | шәһәр яны элемтәсендә | | | | |
| 7.3 | шәһәрара элемтәдә | | | | |
| 7.4 | Транспорт белән алып бару хезмәте күрсәтүнең башка төрләре | | | | |
| 7.5 | башкалар | | | | |
| | | | | | |

Искәрмә:
1. Әлеге таблицаның 5, 6, 7 нче юллары финанс нәтиҗәләре турындагы хисап нигезендә (2300 юл күрсәткеченә бертигез итеп (салым салуга керем (югалту)) тутырыла.
2. Транспорт белән алып бару хезмәте күрсәтүнең башка төрләре заказлар һ.б. буенча транспортта алып бару дигәнне аңлата.

_________________________ ________________________________

Җитәкче, имза | Фамилиясе, исеме, атасының исеме

3.1 нче таблица

______________________________________________________________________

(транспорт белән алып бару хезмәтен күрсәтүче затның атамасы)

## шәһәр элемтәсендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртүгә тарифлар исәпләмәсенә натураль һәм финанс күрсәткечләрен анализлау

| № т/с | Күрсәткечләрнең исеме | Үлчәү берәмлекләре | Базага кадәрге чор | База чоры | Җайга салынулы чор | База чорына карата %ларда җайга салынулы чор |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| 1 | Алып барылган пассажирлар күләме, барлыгы | мең кеше | | | | |
| | шул исәптән | | | | | |
| 1.1 | юлга түләп йөрүче пассажир <*> | мең кеше | | | | |
| 1.1.1 | билетны акчага сатып алганда | мең кеше | | | | |
| 1.1.2 | 1 барган өчен озак файдаланудагы юл билетлары буенча (электрон янчык) | мең кеше | | | | |
| 1.1.3 | озак файдаланудагы башка төр юл билетлары буенча | мең кеше | | | | |
| 1.2 | ЕСПБ буенча ташламалы категория пассажирлары | мең кеше | | | | |
| 2 | Пассажирлар әйләнеше, барлыгы | мең пасс.км | | | | |
| 3 | Пассажирлар йөртү һәм багаж алып барудан керемнәр, барлыгы: | мең сум | | | | |
| | шул исәптән | | | | | |
| 3.1 | пассажирлар һәм багаж өчен түләүдән <*> | мең сум | | | | |
| 3.1.1 | билетны акчага сатып алганда | мең сум | | | | |
| 3.1.2 | 1 барган өчен озак файдаланудагы юл билетлары буенча (электрон янчык) | мең сум | | | | |
| 3.1.3 | озак файдаланудагы башка төр юл билетлары буенча | мең сум | | | | |
| 3.2 | ЕСПБ буенча ташламалы категория пассажирларының юлга түләвеннән | мең сум | | | | |
| 3.3 | бюджет компенсацияләре | мең сум | | | | |
| 3.4 | | мең сум | | | | |
| 4 | Пассажир йөртү һәм багаж алып баруы чыгымнары, барлыгы | мең сум | | | | |
| | шул исәптән | | | | | |
| 4.1 | автобус йөртүчеләрнең һәм кондукторларның хезмәт хакы | мең сум | | | | |
| 4.2 | иминият кертемнәре (4.1 п. нигезендә) | мең сум | | | | |
| 4.3 | автомобиль ягулыгы | мең сум | | | | |
| 4.4 | майлау материаллары | мең сум | | | | |
| 4.5 | автобусларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау | мең сум | | | | |
| 4.6 | авторезинның тузуы һәм | мең сум | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ремонт | | | | | |
| 4.7 | Амортизацион түләүләр | мең сум | | | | |
| 4.8 | лизинг түләүләре | мең сум | | | | |
| 4.9 | бүтән төрле турыдан-туры чыгымнар | мең сум | | | | |
| 4.9.1 | | мең сум | | | | |
| 4.10 | гомуми җитештерү чыгымнары | мең сум | | | | |
| 4.11 | гомумхуҗалык чыгымнары | мең сум | | | | |
